**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

РЕШЕНИЕ

КАРАР

20.06.2025 ел

№11

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына вәкаләтләрне тапшыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Яңа Әлем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советына Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

- җирлек муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү, муниципаль милек объектларын файдалануга бирү, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итү буенча;
- җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан элек бирелгән вәкаләтләр буенча;
- муниципаль милектәге җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны планлаштыруны һәм оештыруны гамәлгә ашыру;
- җирлекнең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә бирү һәм тартып алу, шул исәптән сатып алу юлы белән дә;
- Җирлек җирләреннән файдалануга җир контролен гамәлгә ашыру;

2. Актаныш муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советының 2006 елның 14 июнендәге 13 номерлы карарының 1 пунктчасының икенче абзацын һәм 2 пунктчасының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Советы рәисе Исламов М.М.